РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОСТУДЕНЕЦКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ СУЫКСУ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» октябрь 2016 ел Иске Суыксу № 9

«Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге территориясендә терекөмөшле лампалар кулланучылардан кулланылган терекөмөшле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары турында»

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары (01.10.2013 ел № 860 редакциясендә) белән расланган, җитештерү һәм куллану калдыклары белән яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләре, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, күчереп йөртү һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган калдыклар белән эш итү кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампаларны җыю һәм туплау, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары (01.10.2013 ел № 860 редакциясендә) белән расланган җитештерү һәм куллану калдыклары белән яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләре, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, күчереп йөртү һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган калдыклар белән эш итү кагыйдәләре нигезендә башкарыла.

2. Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге территориясендә терекөмешле тотылган лампаларны кулланучыларда беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарын әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә (милекче, күпфатирлы йортлардагы урыннардан файдаланучы, күпфатирлы йортларда урыннар милекчеләре булган һәм күрсәтелгән урыннар милекчеләре тарафыннан төзелгән күпфатирлы йортлар белән идарә итү шартнамәсе яисә мондый йортларда гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләрен башкару шартнамәсе булган терекөмешле лампадан файдаланучылардан тыш).

3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары (01.10.2013 ел № 860 редакциясендә) белән расланган, җитештерү һәм куллану калдыклары белән яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләре, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, күчереп йөртү һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә,

сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган калдыклар белән эш итү кагыйдәләренең 10.1 пункты нигезендә, терекөмешле лампалар тартмалары шундый ук зурлыктагы яки мондый лампаларның сакланышын тәэмин итә торган башка тарада кулланылган терекөмешле лампаларны, терекөмеш кебек кулланылган лампаларны җыю һәм урнаштыру урынына кадәр, мөстәкыйль транспортлау мөмкинлеген халыкка аңлатырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Иске Суыксу
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Заһидуллина

Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесенең 2016 елның «13» октябрендәге
9 номерлы карарына кушымта

Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге территориясендә терекөмөшле лампалар кулланучылардан кулланылган терекөмөшле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары

| № | Бина | Адресы |
|---|---|---|
| 1 | Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы | Татарстан Республикасы, Буа районы, Иске Суыксу авылы, Совет урамы, 28 йорт (тел. 8 (84374) 48-2-94) |